**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ БОЛЬШЕКАБАНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул.Южная, дом 1, село. Малые Кабаны
422623, Телефон/факс(84378)4-22-02
E-mail: Bkab.La@tatar.ru

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ОЛЫ КАБАН ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Кәньяк урамы,1 нчы йорт,
Кече Кабан авылы,
422623 Телефон/факс(84378)4-22-02
E-mail: Bkab.La@tatar.ru

2020елның 21 декабрендәге 19 номер

# КАРАР

## Җир кишәрлеген файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү мәсьәләсе буенча гавами тыңлаулар билгеләү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 39 нчы маддәсе, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының “Олы Кабан авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставының 20 нче маддәсе нигезендә, территориянең тотрыклы үсешен, инженерлык транспорт һәм социаль инфраструктураларны үстерүне, гражданнарның һәм аларның берләшмәләренең мәнфәгатьләрен исәпкә алуны тәэмин итү максатларында, Кәримов Рамил Хәниф улы гаризасы нигезендә, КАРАР БИРӘМ:

1. Кадастр номеры 16:24:160201:387, мәйданы 660 кв.м булган җир кишәрлеген.«шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен» «кибет»өчен файдалануның шартлы рөхсәт бирү мәсьәләсе буенча: ТР, Лаеш муниципаль районы, Кече Кабан авылы, Үзәк ур., 43 адресы буенча халык алдында тыңлаулар билгеләргә .

2. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Олы Кабан авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелешләр кагыйдәләре проектын әзерләү комиссиясенә 2021 елның 12 гыйнварында 17.00 сәгатьтә Олы Кабан авыл җирлеге башкарма комитеты бинасында Татарстан Республикасы, Лаеш муниципаль районы, Кече Кабан авылы, Көньяк ур., 1 йорт адресы буенча гавами тыңлаулар уздырырга.

3. Ачык тыңлауларга чыгарыла торган мәсьәлә буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләрне язма рәвештә түбәндәге адрес буенча җибәрергә: Татарстан Республикасы Кече Кабан авылы Лаеш районы Южная ур., 1 йорт яисә факс (8843) 4-22-02 буенча 2021 елның 11 гыйнварына кадәр.

4. Әлеге карар «Кама ягы» (Камская новь) район газетасында, Интернет мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru веб – адресы буенча һәм Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында http://laishevo.tatarstan веб – адресы буенча басылып чыгарга, шулай ук Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Олы Кабан авыл җирлеге территориясендә урнашкан мәгълүмат стендларында урнаштырылырга һәм (халыкка җиткерелергә) тиеш.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

**Олы Кабан авыл җирлеге**
**Башкарма комитеты җитәкчесе** **Р.Ш.Илһамов**